Мәмәшир авыл җирлеге Советы

КАРАР

20.11.2024 ел № 33

Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 31 октябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 8 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 10 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 17 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 7 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 30 номерлы, 2023 елның 18 декабрендәге 35 номерлы, 2024 елның 6 нчы февралендәге 6 номерлы, 2024 елнын 21 маендагы 15 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нчы бүлектә:

3 пунктта «, сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – Мәмәшир авыл җирлеге авыл җирлеге Уставы нигезендә төзелә торган Мәмәшир авыл җирлеге җирле үзидарә органындагы җирле үзидарә органы яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе булган вазыйфа.»;

8 пунктта «муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрен,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 6 нчы бүлектә:

1 пунктның 5 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1. пунктының 4 нче пунктчасында «, сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 9 бүлекнең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт узуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр тыела:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү - түбәндәге очракларда:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына йә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасына сайланган яисә билгеләп куелган, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелган очракта;

б) муниципаль вазыйфага сайланган яисә билгеләп куелган очракта;

в) һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органында түләүле сайланулы вазыйфага сайлану очрагында;

2) коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә бирү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә бирү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнү;

4) әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә турыдан-туры аңа буйсынган яисә контрольдә тотылган җирле үзидарә органында ышанычлы яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булу;

5) вазыйфаи хәлгә яисә вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан түләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка түләүләр) алу. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр тарафыннан алынган бүләкләр муниципаль милек дип танылa һәм муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына акт төзеп тапшырыла, Россия

Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очраклардан тыш. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләген тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

6) физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән командировкаларга чыгу тыела, җирле үзидарә органының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, шулай ук чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит ил коммерцияле булмаган оешмалары белән килешүе буенча үзара аңлашу нигездә башкарыла торган командировкалардан тыш;

7) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле булмаган максатларда матди-техник, финанс һәм башка тәэмин итү чараларын, башка муниципаль мөлкәтне файдалану;

8) федераль законнар нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган хезмәт мәгълүматын муниципаль ҳезмәткә бәйле булмаган максатларда тарату яисә куллану;

9) җирле үзидарә органы һәм аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата, әгәр бу аның вазыйфаи бурычларына кермәсә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, гавами фикерләр, уйлар һәм бәяләүләргә юл кую;

10) муниципаль берәмлек башлыгының язма рөхсәтеннән башка чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең, әгәр аның вазыйфаи бурычларына күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек керсә, бүләкләрен, мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш) алу;

11) сайлау алды агитациясе өчен, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча агитация өчен вазыйфаи нигезләмә өстенлекләреннән файдалану;

12) үз вазыйфаи хәленнән сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр мәнфәгатьләрендә файдаланырга, шулай ук күрсәтелгән берләшмәләргә муниципаль хезмәткәр сыйфатында мөнәсәбәтне ачыктан-ачык белдерү;

13) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структураларын төзү яисә күрсәтелгән структураларны (һөнәри берлекләрдән, шулай ук ветераннар һәм башка үзешчән иҗтимагый органнардан тыш) төзүгә булышлык итү;

14) хезмәт бәхәсен җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларны үтәүне туктатырга;

15) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтчелек советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә эш итүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керү;

16) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, яллаучы (эш бирүче) вәкиленең язма рөхсәтеннән башка бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү.

1.4. 12 бүлек 1.3 пунктының 5 пунктчасында «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә»;

1.5. 14 өлешнең 2 пунктындагы 6 пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 19 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарә органы бетерелүгә бәйле рәвештә яисә җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты кыскартылу сәбәпле муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә, оешма ябылу йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылу сәбәпле алар эштән азат ителгән очракта муниципаль хезмәткәргә хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы : И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702